ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы вәкиллекләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 494-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы вәкиллекләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 494-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2023 елның 19 октябре
№ 2174-VI ДС

494-6 номерлы проект
Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кетрелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**«Татарстан Республикасы вәкиллекләре турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

1 статья

«Татарстан Республикасы вәкиллекләре турында» 2003 елның 10 ноябрендәге 47-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003 № 11; 2007, № 7 (I өлеш); 2014, № 6 (I өлеш); 2015, № 12 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда:
а) дүртенче өлешне үз көчен югалткан дип танырга;
б) бишенче өлештә «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимияте органнары» сүзләренә алмаштырырга;

2) 3 статьяда «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәис)» сүзләренә алмаштырырга;

3) 5 статьяда «учреждениеләре, оешмалары һәм предприятиеләре» сүзләрен «оешмалары» сүзенә алмаштырырга;

4) 9 статьяның икенче өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәис)» сүзләренә алмаштырырга;

5) 10 статьяның дүртенче өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәис)» сүзләренә алмаштырырга;

6) 11 статьяның беренче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Татарстан Республикасы вәкиллекләре үз компетенциясе чикләрендә һәм Татарстан Республикасы башлыгы (Рәис), Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы башлыгы (Рәис) Администрациясе җитәкчесе, Татарстан Республикасы вәкиллекләре эшчәнлеген координацияләүне гамәлгә ашыруга Татарстан

Республикасы башлыгы (Рәис) тарафыннан вәкаләтле органы йөкләмәләре нигезендә:»;

7) 12 статьяның беренче өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәис)» сүзләренә алмаштырырга;

8) 14 статьяда:
а) беренче өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгының (Рәис)» сүзләренә алмаштырырга;
б) дүртенче өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәис)» сүзләренә алмаштырырга;

9) 15 статьяның икенче өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәис)» сүзләренә алмаштырырга;

10) 16 статьяда икенче җөмләне алып ташларга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы вәкиллекләре турында»
Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»
Татарстан Республикасы закон проектына**

# АҢЛАТМА

«Татарстан Республикасы вәкиллекләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проекты «Татарстан Республикасы вәкиллекләре турында» 2003 елның 10 ноябрендәге 47-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үзгәрешләргә туры китерү максатларында эшләнде.

«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы белән Татарстан Республикасы югары вазыйфаи заты вазыйфасы исеменә төзәтмәләр кертелде.

Татарстан Республикасы законын «Россия Федерациясе субъектларында иҗтимагый хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертелде, алар нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары системасын Татарстан Республикасы башлыгы (Рәис), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, министрлыклар, Татарстан Республикасы Дәүләт комитетлары һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары тәшкил итә (4 статьяның 1 өлеше), шулай ук Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының яңа структурасын билгеләгән «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары системасы һәм структурасы турында» 2023 елның 4 маендагы 276 номерлы Указы чыкты.

Татарстан Республикасы вәкиллекләре Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары структурасына кертелмәгән, моны исәпкә алып, «Татарстан Республикасы вәкиллекләре турында» 2003 елның 10 ноябрендәге 47-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына тиешле үзгәрешләр кертү таләп ителә.

**«Татарстан Республикасы вәкиллекләре турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә**
**үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга,**
**үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле**
**Татарстан Республикасы законнары һәм башка**
**норматив хокукый актлары**
**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы вәкиллекләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

«Татарстан Республикасы вәкиллекләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Президентының түбәндәге Указларына һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларына үзгәрешләр кертү таләп ителәчәк:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Әзербайҗан Республикасындагы даими вәкиллеге турында» 1992 елның 31 декабрендәге ПУ-605 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Франция Республикасында тулы вәкаләтле вәкиллеген булдыру турында» 1994 елның 7 июлендәге ПУ-452 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Свердловск өлкәсендә даими вәкиллеген булдыру турында» 1996 елның 25 маендагы ПУ-312 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Санкт-Петербург шәһәрендә һәм Ленинград өлкәсендә даими вәкиллеген оештыру турында» 1996 елның 25 маендагы ПУ-314 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Казахстан Республикасында тулы вәкаләтле вәкиллеген булдыру турында» 1997 елның 10 сентябрендәге ПУ-464 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Төркия Республикасында тулы вәкаләтле вәкиллеген булдыру турында» 1997 елның 13 сентябрендәге № ПУ-493 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Үзбәкстан Республикасында вәкиллеген булдыру турында» 2005 елның 28 февралендәге № ПУ-67 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Россия Федерациясендә тулы вәкаләтле вәкиллеге турында нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 8 сентябрендәге № ПУ-346 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Чехия Республикасындагы Сәүдә-икътисадый вәкиллеге турында» 2008 елның 23 гыйнварындагы № ПУ-18 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Төрекмәнстанда тулы вәкаләтле вәкиллеген булдыру турында» 2009 елның 11 августындагы № ПУ-421 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Башкортостан Республикасында даими вәкиллеген булдыру турында» 2011 елның 5 мартындагы № ПУ-107 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Кырым Республикасында һәм Севастополь шәһәрендә даими вәкиллеге турында нигезләмәне раслау хакында» 2015 елның 6 маендагы № ПУ-428 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Куба Республикасында сәүдә-икътисадый вәкиллеге турында» 26.08.1999 елның 26 августындагы 558 номерлы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Финляндия Республикасындагы сәүдә-икътисадый вәкилен билгеләү турында» 2000 елның 22 гыйнварындагы 32 номерлы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Ханты-Манси автономияле округында сәүдә-икътисадый вәкиллеген оештыру турында» 2001 елның 5 маендагы 257 номерлы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Түбән Новгород өлкәсендә сәүдә-икътисадый вәкиллеген оештыру турында» 2001 елның 17 октябрендәге 767 номерлы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Саратов өлкәсендә сәүдә-икътисадый вәкиллеген оештыру турында» 2002 елның 18 июнендәге 345 номерлы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Швейцария Конфедерациясендә сәүдә-икътисадый вәкиллеген оештыру турында» 2002 елның 19 сентябрендәге 547 номерлы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы вәкиллекләренең дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм Татарстан Республикасы оешмалары белән үзара хезмәттәшлегенең нәтиҗәлелеген арттыру турында» 2003 елның 27 сентябрендәге 512 номерлы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының сәүдә-икътисадый вәкиллекләре турында» 2006 елның 2 августындагы 399 номерлы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Чехия Республикасындагы сәүдә-икътисадый вәкиллеге турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2008 елның 8 маендагы 295 номерлы какрары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Башкортостан Республикасында даими вәкиллеге турында» 2011 елның 19 июлендәге 571 номерлы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Дубайда (Берләшкән Гарәп Әмирлекләре) сәүдә-икътисадый вәкиллеген оештыру турында» 2013 елның 30 маендагы 364 номерлы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Кытай Халык Республикасында сәүдә-икътисадый вәкиллеген оештыру турында» 2014 елның 1 октябрендәге 707 номерлы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Германия Федератив Республикасында сәүдә-икътисадый вәкиллеген оештыру турында» 2019 елның 3 августындагы 641 номерлы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы вәкиллекләре эшчәнлеген индикатив бәяләү турында» 2023 елның 25 гыйнварындагы 41 номерлы карары.

**«Татарстан Республикасы вәкиллекләре турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы закон проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы вәкиллекләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә акча бүлеп бирүне таләп итмәячәк.